СӨЙ ГОМЕРНЕ, СӨЙ ХАЛЫКНЫ, СӨЙ ХАЛЫКНЫҢ ДӨНЬЯСЫН!

# ДУСЛЫК

ОКТЯБРЬ РАЙОНЫ ХАЛЫК ГАЗЕТАСЫ
НАРОДНАЯ ГАЗЕТА ОКТЯБРЬСКОГО РАЙОНА

Газета 1931 елның 1 июленнән бирле чыга | №108 (7437) | 10 сентябрь, 1992 ел. ПӘНҖЕШӘМБЕ | Бәясе 4 тиен.

## Семинар үтте

8 сентябрь көнне «Большевик» колхозы базасында хуҗалык җитәкчеләре, баш инженерлар, баш агрономнар, авыл хуҗалыгы, азык-төлек идарәсе белгечләре катнашында район семинары үтте. Анда төп тема итеп чөгендер алуны дөрес оештыру мәсьәләсе куелды. Район администрациясе башлыгы Ш. В. КАШАПОВ, семинарны ачып, район тормышындагы соңгы хәбәрләр белән таныштырды, кыр эшләре буенча алда торган бурычларга тукталды. Хәзер төп көчне икенче урак — чөгендер алуга тупларга, аны мөмкин кадәр югалтуларсыз алуны оештырырга кирәклегенә басым ясады. Аннан авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсенең баш агрономы Н. МУСИН быелгы чөгендер сезонының үзенчәлекләреннән чыгып, әлеге кампанияне отышлы үткәрү буенча конкрет киңәшләр бәян итте.

Исәпләүдән күренгәнчә аны югалтуларсыз җыеп алганда районның планны үтәү мөмкинлеге бар. Шуңа баш агроном чөгендер алуга кырны әзерләү, рәт араларын исәптә тотып комбайннарны чөгендер алуга дөрес төшерү, комбайннарны, чистарту җайланмаларын көйләү тәртибен аңлатты, аны ташу барышында игътибарлы булырга кирәклекне күрсәтте.

Аннан «Гостехнадзор» инспекциясе начальнигы Р. Саттаров чөгендер алу техникасын — БМ-6Б, ОГД-6 чистарту җайланмасын көйләүне, авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе баш инженеры И. Мостафин МКК-6-0,2 чөгендер алу комбайнын һәм СПС-4,2 төяү җайланмасын регулировкалау тәртибен практикада күрсәттеләр.

Идарәнең план-экономика бүлеге начальнигы Р. ШӘЙХЕТДИНОВ чөгендерчеләр хезмәтенә түләү тәртибен аңлатты.

Семинарда шикәр заводы директоры урынбасары Ә. Лотфуллин чималны кабул итү шартлары һәм тәртибе белән таныштырды, бу җәһәттән туган сорауларга җавап бирде. Семинарны янә Н. Мусин дәвам итте. Ул схемаларда шикәр чөгендере астына җир әзерләү технологиясен җентекләп аңлатты. Шундый ук тәртиптә тунга сөрү технологиясе турында кабат искә төшерде, «Большевик» колхозы кыры мисалында аны практик карау булды. Җирне дөрес карау, эшкәртү, аны минераль ашламалар белән ашлауның уңышны күтәрүдә төп алшарт булуын ассызыклады. Аннан ул бүген уҗым чәчү һәм тунга сөрүнең барышына анализ ясады. Бүгенге көнгә 12 хуҗалык уҗым чәчүне тәгәлләде, байтагы аны тәмамлау алдында. Әмма «Правда», «Алга» колхозлары, «Мамык» совхозында эш күләме әле байтакка җыела. Тунга сөрү исә планга карата 42 процентка гына башкарылды.

Район авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе начальнигы Ә. Н. РӘХМӘТУЛЛИН бүгенге көндә терлекчелектә эшләрнең торышына кыскача анализ ясады.

Семинар эшенә йомгакны район администрация башлыгы Ш.В. Кашапов ясады. Ул авыл хуҗалыгында һәр тармакта эшне зур таләпчәнлек белән, сыйфатлы итеп оештырылуына ирешүнең төп максат булуын ассызыклап, бу җәһәттән җитәкчеләр һәм белгечләргә таләпчәнлекне бермә-бер күтәрү кирәклегенә басым ясады, алда торган бурычларны бәян итте.



— Һәр эштә дә өлгер ул, — диләр Евгений Мамонтов турында. Чыны да шулай, уңган егет ул, хезмәтенең нинди дә талымлап тора торганнардан түгел. Үзе киң профильле механизатор, техниканың теләсә кайсын идарә итә ала.

Печән өсте җитүгә аны АВМ-0,65 агрегатына куйдылар. Хезмәтенә күңел биреп алынды ул, кырдан кайткан яшел массаны кыйммәтле мал азыгына әверелдерде.

Байтак хуҗалыкларда витаминлы үлән оны хәзерләүне капчык җитмәгәнгә сылтап акрын темпларда алып бардылар. Мамонтов исә үлән онын әрҗәләргә бушатып суыту вариантын тәкъдим итте. Шулай агрегат нәтиҗәле эшләде, 100 тоннага якын каротинга бай азык туплап куелды.

Бу эшне тәгәлләүгә Евгений тракторга күчеп утырды. Бу көннәрдә ул Т-150 белән тунга сөрүдә тырышып хезмәт куя.

Рәсемдә: «1 нче Май» колхозы механизаторы Е. Мамонтов.

## Кайда? Ничек?

**Район хуҗалыкларында терлек азыгы хәзерләүнең торышы.**

(Мәгълүматлар 1992 елның 7 сентябренә).

Беренче багана — хуҗалыклар исемнәре, икенче — хәзерләнгән силос (процентларда), өченче — 1 шартлы малга хәзерләнгән азык берәмлеге (центнерларда).

| | | |
|---|---|---|
| Синдряков исем. | 91 | 28,7 |
| Ульянов исем. | 30 | 18,3 |
| «Правда» | 15 | 15,0 |
| «Восход» | 53 | 16,7 |
| Мичурин исем. | 132 | 25,7 |
| «Россия» | 86 | 20,3 |
| Хафизов исем. | 71 | 13,6 |
| «Путь к коммунизму» | 131 | 19,6 |
| Муса Җәлил исем. | 51 | 24,3 |
| «Родина» | 19 | 17,3 |
| «Игенче» | 108 | 22,5 |
| «Большевик» | 54 | 22,4 |
| «Заветы Ильича» | 45 | 19,1 |
| «Знамя Октября» | 59 | 12,7 |
| «Алга» | 18 | 14,6 |
| «Комбайн» | 10 | 12,6 |
| XXI партсъезд исем. | 33 | 21,6 |
| «Татарстан» | 53 | 23,9 |
| «40 лет Победы» | 47 | 19,4 |
| «Чишмә» | 46 | 17,0 |
| «Таң» | 36 | 20,0 |
| «Москва» | 90 | 24,5 |
| «Үрнәк» | 34 | 18,2 |
| «Лесная поляна» | 4 | 14,3 |
| «Кондырча» | 103 | 20,5 |
| Кузнецов исем. | 6 | 13,9 |
| «Заря» | 101 | 20,5 |
| «Чирмешән» | 41 | 16,4 |
| «Ленинский путь» | 93 | 14,6 |
| «Беренче май» | 55 | 15,5 |
| «Яшь көч» | 114 | 18,3 |
| «Төрнәс» совхозы | 11 | 9,3 |
| «Мамык» совхозы | 53 | 25,6 |
| «Рассвет» совхозы | 36 | 18,4 |
| «Сөлчә» совхозы | 32 | 4,6 |
| Хуҗалыкара берләшмә | 56 | 11,3 |
| «Дуслык» | 84 | 26,4 |
| Район буенча | 53 | 18,0 |

## Хәлиткеч чор җитә

Терлекчелектә катлаулы һәм хәлиткеч чор — кышлату чоры якынлаша. Бу периодка гадәттә мул азык запасы туплап, терлекчелек биналарын ныклы ремонтап керешәләр, шул чакта гына маллардан мул продукция алуга исәп тотарга була. Хуҗалыкларга моның әһәмиятен аңлатып тору артык, алар аны беләләр инде. Әмма бу мөһим эшкә бөтен җирдә дә бертөрле караш яши дип әйтеп булмый әле.

Дөрес, Синдряков исемендәге, «Татарстан», «Кондырча», «Ленинский путь», «Россия» колхозларында, «Рассвет» совхозында елның-елында бу эшкә җаваплы карыйлар. Биредә малларны җәйләүгә озатуга ремонт звенолары оештырыла, алар абзарларны кышкы чорга төзәтеп, ремонтлап, чистартып- дезинфекцияләп куялар. Быел да әлеге хуҗалыкларда ферма биналары малларны бүгеннән кабул итүгә әзер. Моннан тыш суыткыч җайланмалары, лабораторияләр, ясалма орлыкландыру пунктлары да бер дигән итеп әзерләнгән, терлекчеләр йортлары да тәртипкә салынган. Мондый шартларда эш башлавы да күңелле, әлбәттә. Агымдагы елда байтак кына хуҗалыкларда терлекчелек биналарын яңартуга да игътибар бирделәр. «Татарстан» колхозында 160 башка бозаулар абзары, Муса Җәлил исемендәге колхозда 60 башка исәпләнгән дуңгызлар фермасы, «Родина»да бәрәннәр өчен ферма төзелде, анда сарык фермасы, «40 лет Победы»да атлар абзары төзелеп килә. Яңа биналарда терлекләрне заманча карау өчен бөтен уңайлыклар күздә тотылган була.

Әмма биналарны ремонтлау эшен хәзергә хәтле сәбәпсез сузучы хуҗалыклар да юк түгел. Муса Җәлил исемендәге колхозда, мәсәлән, фермаларга ремонтчылар кулы бөтенләй кагылмаган: тәрәзәләр ватык, ишекләр, идәннәр кыйшайган, бина агартылмаган, «Мамык» совхозында да елның-елында ремонт эше соңга калып, ашык-пошык кына башкарыла. Быел «Москва», «Знамя Октября», «Чишмә», Кузнецов исемендәге колхозларны бу җәһәттән мактап булмый. Ә бит әлеге колхоз-совхозларда ремонтны сыйфатлы итеп, үз вакытында үткәрү өчен бөтен шартлар да бар иде. Ни генә булмасын, вакыт көтми, 1 октябрьдән малларны ябык биналарга күчерү ихтималына исәп тотарга кирәк. Моның өчен 20—25 сентябрьгә ферма объектларын тулысы белән көйләп бетерергә, малларны кабул итәргә әзер булырга кирәк.

Быел кышлату җиңеллердән булырга охшамый. Кышлату чорына бер шартлы терлеккә 35—40 центнер азык берәмлеге исәбеннән азык туплау бурычы куелган иде. Терлекләр өчен азык әзерлим дигән кешегә ел бик кулай килде. Хәзер силос салу белән бергә катнаш силос әзерләүгә дә нык игътибар бирү кирәк. Туклыклылык ягыннан бик кыйммәт булган бу төр азык әле бездә планга карата 19 процентка гына үтәлде. «Төрнәс», «Мамык» совхозлары, «Москва», «Алга» колхозлары аны бөтенләй әзерләмиләр. Кышкы чорда азык цехларын тулы куәтенә эшләтү турында да хәзердән кайгырту шарт. Бу яктан «Татарстан» колхозы күпләргә үрнәк булып торырлык.

Быелгы кышлату бездән аерата тырышлык соравын да онытмаска кирәк.

Быелның 1 сентябренә сыерларның продуктлылыгы узган елның шул чоры белән чагыштырганда 28 килограммга азрак, шуңа да ел азагына кадәр әлеге аерманы бетерү безнең өчен төп бурыч. Шуңа да җәйләүдән кышлатуга күчү чорында продуктлылыкның кимүенә һич юл куелырга тиеш түгел. Моның өчен хәзердән үк зур кайгырту алып бару зарур. Бүгеннән үк бозаулату бүлегән комплектларга, чөнки масса күләм бозаулату вакыты җитеп килә. Бер үк вакытта малларны өч тапкыр савуга күчәргә, раздой оештыруны җайга салырга кирәк. Хәзер такаларны комплектлап, аларны каплатуга тотыну да мөһим эш. Аларның авырлыгы 380 килограммнан да ким булырга тиеш түгел. Хуҗалык җитәкчеләре һәм белгечләр кышлату чорына әнә шундый әзерлекне тәэмин итеп керергә тиешләр. Шул чакта гына аны уңышлы үткәрәсенә өмет тотарга була.

**Х. ФӘТХУЛЛИН,**
авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе зоотехнигы.

## ХЕЗМӘТЕН ХӨРМӘТЛӘП

Халык мәгарифе өлкәсендәге күренекле хезмәтләре өчен Татарстан Республикасы Президенты Указы белән Октябрь районы администрациясе башлыгы каршындагы халык мәгарифе бүлеге мөдире НӘБИУЛЛА ХӘЙРУЛЛА улы АБДУЛЛИНга «Татарстан Республикасы мәктәпләренең атказанган укытучысы» дигән мактаулы исем бирелде.

# Беренче рәхмәт

Солдат озаткан гаиләләрнең бөтенесен берләштергән бер уртак сыйфат бар: улларын йорттан чыгарып җибәреп, күз төбендәге яшьләрен сөртәләр дә шушы көннән ук аннан хәбәр көтә башлыйлар. Шул көннән хат ташучы аларның иң якын дусларына, сердәшләренә әверелә. Ерактан улы—йөрәк бәгыре кулы белән язылган беренче хәбәре килгәнче аның белән әллә ничә кат күрешеп сөйләшергә, хатын-кызларча көтү хәлләрен уртаклашырга өлгерәләр алар. Һәм, ниһаять, ул көн килеп җитә! Хат ташучы тапшырган ул кадерле хәбәр бөтен гаилә белән җыелып ачыла, ана кайгыртуыннан, гаилә җылысыннан читтә беренче айларын үткәргән яшь солдатның тәүге хатындагы һәр җөмлә аналарга гына хас сиземләү, тою белән тулыландырып, керфеккә кунган яшь, тамакка тыгылган төер белән аралаштырып кабат-кабат укыла.

—И, балакай, сагына булыр, сиздермәгән генәдер инде.

—Әбисен дә сорашкан.

—Киенеп йөрсен иде, кышкы як бит.

—Тамагы туя микән? Тәмле ашарга бик ярата иде.

Һай, ул беренче көннәрнең озынлыгы! Беренче хатларның һәр юлы укый-укый күңелгә сеңеп кала. Ул көннәр Вәлиевлар гаиләсендә дә булды. Уллары Илшатның чик буеннан, ерак Амур өлкәсеннән беренче хаты килүенә елга якын вакыт үтте. Бүген аларның гаилә архивында Илшатның төптөгәл 37 данә хаты саклана. Үскәндә тыйнак кына, аз сүзле тоелган Илшатның читкә киткәч гаҗәеп йомшак күңелле, кайгыртучан ул булуы ачыкланды. Һәм иң куанычлысы— шәһәрнең 2 нче мәктәбендә бергә укыган классташлары, укытучылары, хезмәттәшләре дә аны әчкерсез якын күргәннәр, ятратканнар. Әле дә аның ярдәмчелләген сабырлыгын сагынып искә алалар, техника белән мавыгуын,балыкчы хирыслыгыннан чыккан мәзәкләрен сөйләргә яраталар.

Ә Илшат хатларны иренмичә яза. Хатларыннан күренгәнчә, спорт белән шөгыльләнгән, хезмәттән курыкмаучы, гаиләдә әйбәт тәрбия алган, төптән фикер йөртүче, җитди холыклы егеткә солдат хезмәте бер дә авыр бирелми, иптәшләре дә яхшылар икән. Соңгы хатларының берсендә үзен ялга җибәрергә җыенуларын да әйтеп язган иде. И ул әни кеше— Зөлфия апаның хәзерләнүләре, хезмәт вазифасы буенча кырыс холыклы булырга тиешле милиция майоры Надыйр абыйның, үз малае кебек күреп үстерешкән Галия апаның, апасы Люциянең көтүләре, нәни Ләйләнең абыйсы фотосы белән сөйләшүләре! Кайтсын иде, әтисенә 50 яшь тулган көннәрдә биредә булсын иде, дип торган көннәрдә, хат ташучы аларга серле елмаеп бер конверт тоттырды.

Таныш булмаган кул белән язылган конверт эчендә—рәхмәт хаты иде!

«Хөрмәтле Надыйр Нәгыймович һәм Зөлфия Мифтаховна!

Сезнең улыгыз Илшат чик буе гаскәрләрендә хезмәт итә, Илебез иминлеген саклауда җаваплы һәм мактаулы эш башкара.

Вәлиевлар хатны кулдан-кулга йөртеп берничә кат укып чыктылар.

«Коллективта аны хезмәт сөючән һәм башкаручан, җитәкчеләр һәм иптәшләре арасында урынлы хөрмәткә лаек сугышчы буларак беләләр... Сез илебезнең изге чикләрен саклаучы улыгыз белән чын күңелдән горурлана аласыз.

Командование сезгә шундый ул үстерүегез өчен рәхмәт белдерә, эшегездә уңышлар, сәламәтлек һәм шәхси бәхет тели».

—Әтисенең юбилеена иң зур бүләкне Илшат ясады, рәхмәт яугыры,—диде Галия әби кәгазьне әйләндергәләп.

Шулай булып чыга да! Ата-ана өчен балаң турында яхшы сүздән дә кадерле, сөенечле хәл булуы мөмкинме? Рәхмәт кәгазе кадерләп гаилә архивындагы Илшат хатлары янына куелды.

Гомуми төргәктә ул 38 нче иде, ә Илшатның мөстәкыйль тормыш юлында андый хат әле тәүгесе генә иде. Соңгысы булмаска тиеш! Игелекле, бик киң холыклы, тәртипле гаилә тәрбиясе аңа бар гомеренә шулай дәрәҗәле, хөрмәтле булып яшәргә нигез бирде.

**С. НУРУЛЛИНА.**

# ДУСЛЫК

## Хөрмәтле укучылар!

**Кабат исегезгә төшерәбез: «Дуслык», «Дружба», «Туслах» район газетасына язылу дәвам итә. Газетага үзвакытында язылып калырга киңәш итәбез. Аның еллык бәясе 78 сум.**



**Тагын килер әле Сабан туйлары...**
**Р.Гыйльметдинов фотосы.**

# ТЕЛЕВИДЕНИЕ

**КАЗАН КҮРСӘТӘ**
**12 СЕНТЯБРЬ**
**ШИМБӘ**

7.00—8.00 «Чулпан». Информацион-музыкаль программа.
17.40 «Виктория» студиясе бию ансамбле чыгышы.
18.00 Татарстан телевидениесе фондыннан. «Беренче театр».
19.00 Татарстан.
19.30 Гөлзада Сафиуллина җырлый.
20.30 Әлли-бәлли-бәү.
20.40 «Шигърият». «Гомер тирәге». Роберт Әхмәтҗан.

**ОСТАНКИНО КАНАЛЫ**

7.00 Яңалыклар.
7.20 Иртәнге гимнастика.
7.30 Эшлекле кешенең шимбә иртәсе.
8.30 Спорт-шанс.
9.00 Уңышка ничек ирешергә?
9.15 «Марафон-15».
9.40 Бумеранг.
10.10 «Труба» радиосы.
10.40 Медицина синең өчен.
11.20 Афәрин.
12.20 Экология хроникасы.
12.40 Япония телевидениесе программасы. «Кеше тәне: яңа тормыш туу».
13.35 Балалар һәм үсмерләр телепрограммаларының III халыкара фестивалендә.
13.55 «Икенче чынбарлык». 2 фильм. «Утраулар».
15.00 Яңалыклар.
15.25 «Кубань казаклары». Нәфис фильм.
17.40 «Кызыл квадрат».
18.20 Хайваннар дөньясында.
19.00 Янутлар». Мультфильм. 4 серия.
19.35 «Һәлак булган альпинист» кунакханәсе». Нәфис фильм.
20.45 Тыныч йокы, нәниләр.
21.00 Яңалыклар.
21.40 Брейн-ринг.
23.35 «Париж—Мәскәү—Пекин» авторалли. Тәнәфестә—Яңалыклар.
00.20 «Куплетны җырлап бетермичә». Игорь Тальков истәлегенә.

**РОССИЯ КАНАЛЫ**

8.00, 14.00, 20.00 Хәбәрләр.
8.20 Александр Свирский.
9.00 Спорт дөньясы «Җиллет» фирмасы күзлегеннән караганда.
9.30 ««03» программасы.
10.00 АКШның теннис буенча ачык чемпионаты.
11.00 «Плюс унбер» видеоканалы.
12.25 Ничек яшәрбез?
13.00 Пилигрим.
13.45 «Көньяк Курил. Проблема нәрсәдә?»
14.25 «Тылсымчыны урлау». Нәфис фильм.
16.05 «Бурда моден» тәкъдим итә.
16.35 XX гасыр кадрда һәм кадр артында. «Водород бомбасы турында чын дөресе һәм уйдырма».
21.00 «Хануссен». Нәфис фильм.
23.20 «А» программасы.
00.05 АКШның теннис буенча ачык чемпионаты.

**КАЗАН КҮРСӘТӘ**
**13 СЕНТЯБРЬ**
**ЯКШӘМБЕ**

7.00—8.00 «Чулпан». Информацион -музыкаль программа.
16.55 Мультфильмнар.
17.20 «Селявидео».
18.05 М. Маликова. «Оҗмах балалары». Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры спектакле.
19.55 Әлли-бәлли-бәү.
20.05 Керәшен кардәшләр мәйданы.

**ОСТАНКИНО КАНАЛЫ**

7.00 Рухи көч сәгате.
8.00 «Спортлото» тиражы.
8.15 Мультфильм.
8.35 Болгариянең фольклор коллективлары концерты.
9.05 Иртән иртүк.
9.35 Япония телевидениесе программасы. «Кардагы алмалар».
10.05 Бар да мөмкин.
10.35 Иртәнге йолдыз.
11.25 Сез моны булдыра аласыз.
12.05 Язучы Э. Лимонов белән очрашу.
13.05 «Марафон-15».
14.00 «Сынлы сәнгать метаформозалары». 5, 6 серияләр.
15.00 Яңалыклар.
15.20 Туры эфирда диалог.
16.00 Сәяхәтчеләр клубы.
17.30 Телелоция.
17.45 Уолт Дисней тәкъдим итә.
18.35 Я. Сибелиус. «Сагышлы вальс».
18.45 Яңалыклар.
19.00 «Цунами». Н. Задорнов романнары буенча нәфис-публицистик фильм.
20.00 Кино яңалыклары.
20.35 «Малайлар». Нәфис фильм.
22.00 Йомгаклар.
22.45 Спорт уикэнды.
23.00 «Монро һәм Мадонна».
00.00 Яңалыклар.
00.25 Видеодром.
00.55 Мюнхгаузен-клуб.

**РОССИЯ КАНАЛЫ**

8.00 Хәбәрләр.
8.20 Чыганаклар.
9.00 Ышансагыз, ышанмагыз...
9.30 АКШның теннис буенча ачык чемпионаты.
11.00 «Патшалыктагы маҗара». Мультфильм. 3 серия.
11.25 «Аты-баты»...
12.55 Россия энциклопедиясе. «Теге дөньядан».
14.20 «Дораэмон». Мультфильм.
14.55 «Сезне Виктор Светлов чакыра».
15.40 Л. Пантелеев. «Ышанам».
21.25 «Декамерон төннәре». Нәфис фильм.
23.20 Спорт каруселе.
23.30 «Төнге актер клубы».

*● Моны белү кызыклы...*

## Сабыйлар нигә елый?

Бельгий газетасы «Суяр» ның хәбәр итүенчә, Израильдәге Бен Гурион исемендәге университет галимнәре сабый балаларның ни өчен елауларын билгеләп торган компьютер иҗат иткәннәр.

Бишек янына куелган бу прибор, акустик чаралар ярдәмендә, имчәк балалары елавының төрле типларын тотып ала. Ул моның сәбәпләрен дә ачыклап бирә —бала арыганлыктан, төрле авыру аркасында, ач булудан яки эчәсе килүдән еларга мөмкин.

## Ерткычлар патшасы—сакчы

Харьков өлкәсенен Кюрипинен шәһәрендә күптән түгел кызыклы алыш-биреш булды. Җирле ремонт —транспорт предприятиесенең бер хезмәткәре биредә гастрольгә килгән циркта кечкенә арыслан баласы сатып алды. Әйтергә кирәк, бу ерткычны ул мәгълүм максат белән булдыруын әйтте. «Хәзер караклар этләрдән генә курыкмыйлар», —дип аңлатты сатып алучы. Аның үз йорт җирен саклыйсы килә.

## *12 яшьлек ана*

Сретенск шәһәрендә яшәүче бер кыз 12 яшендә анага әверелде. Чита өлкәсе балалар шифаханәсе хезмәткәрләренең әйтүенчә, биредә 13—14 яшьтән бала тудыру күптән инде сирәк хәл түгел иде. Ә менә 12 яшьлек ана беренче тапкыр очрый. Аны тулы хокук белән Байкал артының рекордчысы дип атарга мөмкин.

**Татарстан яңалыклар агентлыгы (ТАН)**

**МӨХӘРРИР В. В. ИСХАКОВ.**

**«Дуслык» газетасы атнаның сишәмбе, пәнҗешәмбе, шимбә көннәрендә чыга һәм рус, чуваш телләренә тәрҗемә ителә.**
**Татарстан Республикасы информация һәм матбугат Министрлыгының Норлат Октябрь типографиясе.** Тираж 3750.